КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 апрель г.Казань № 379

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль берәмлек чикләрендә балалар өчен билгеләнгән мәгариф оешмалары, балалар медицина, шифаханә-курорт, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары, балалар ялы һәм сәламәтләндерү оешмалары турында белешмәләр урнаштыру тәртибен раслау хакында

«Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль берәмлек чикләрендә балалар өчен билгеләнгән мәгариф оешмалары, балалар медицина, шифаханә-курорт, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары, балалар ялы һәм сәламәтләндерү оешмалары турында белешмәләр урнаштыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 декабрь, 1259 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль берәмлек чикләрендә балалар өчен билгеләнгән мәгариф оешмалары, балалар медицина, шифаханә-курорт, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары, балалар ялы һәм сәламәтләндерү оешмалары турында белешмәләр урнаштыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан балалар өчен билгеләнгән мәгариф оешмалары, балалар медицина, шифаханә-курорт, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары, балалар ялы һәм сәламәтләндерү оешмалары өчен билгеләнгән белешмәләр (алга таба - оешмалар турында белешмәләр) урнаштыру кагыйдәләрен билгели.

2. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлеше нигезендә балалар арасында тарату өчен тыелган мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати продукция таратучыларга мәгълүмат бирү максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы ел саен, 1 мартка кадәр һәм 1 сентябрьгә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында (алга таба - муниципаль берәмлек сайты) оешмалар турындагы белешмәләрне актуальләштерә.

3. Оешмалар турында белешмәләрдә булырга тиеш:

оешманың адресы;

оешманың тулы исеме;

оешманың фирма исеме (коммерция оешмалары өчен).

4. Оешмалар турында белешмәләр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча PDF форматында урнаштырыла.

5. Оешмалар турында белешмәләр урнаштыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы «Балалар арасында мәгълүмат тарату өчен тыелган мәгълүмат продукциясен таратучылар өчен белешмәләр» дигән махсус бүлекне муниципаль берәмлек сайтында төзи, аңа керү муниципаль берәмлек сайтының төп битеннән гамәлгә ашырыла.

6. Оешмалар турында белешмәләр әзерләү максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлек сайтында оешмалар турында белешмәләр урнаштыруга техник мөмкинлек булмаган очракта, оешмалар турында белешмәләр «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль берәмлек чикләрендә балалар өчен билгеләнгән мәгариф оешмалары, балалар медицина, шифаханә-курорт, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары, балалар ялы һәм сәламәтләндерү оешмалары турында белешмәләр урнаштыру тәртибенә кушымта

Форма

Муниципаль берәмлек чикләрендә балалар өчен билгеләнгән мәгариф оешмалары, балалар медицина, шифаханә-курорт, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары, балалар ялы һәм сәламәтләндерү оешмалары турында белешмәләр

| Т/с | Оешманың тулы исеме | Оешманың фирма исеме (коммерция оешмалары өчен) | Оешманың адресы |
|---|---|---|---|
| 1. Мәгариф оешмасы | | | |
| | | | |
| 2. Балалар медицина оешмалары | | | |
| | | | |
| 3. Шифаханә-курорт оешмалары | | | |
| | | | |
| 4. Физкультура-спорт оешмалары | | | |
| | | | |
| 5. Мәдәният оешмалары | | | |
| | | | |
| 6. Балаларның ялын һәм аларны савыктыру оешмалары | | | |
| | | | |

______________________________